| | |
|---|---|
| ГЛАВА ИЛЯКСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2 ноябрь 2020 ел Илексаз авылы № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылы өлешендә 2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Илексаз авылы, Комсомольская урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан Илексаз авылы мәдәният йорты бинасында 2021 нче елның 13 ноябренә 10 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Илексаз авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Илексаз авылында юл корылмаларын буяу өчен буяу, юл тамгасы ясау;

2) Илексаз авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонтлау, вак таш ташу);

3) Илексаз авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилейлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу;

4) Илексаз авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;

5) Илексаз авылында ял итү зонасын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

6) Илексаз авылында ял итү зонасының күрсәтмә билгесен алу;

7) Кыш Бабай һәм Кар кызы костюмы сатып алу;

8) Илексаз авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампочкалар һәм яктырткычлар сатып алу);

9) Илексаз авылы зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);

10) Илексаз авылы зираты өчен үзйөрешле газонокосилки сатып алу;

11) янгын куркынычсызлыгы өчен җиһазлар сатып алу (су өчен савыт сатып алу);

12) Илексаз авылы Комсомол урамы буенча янгын гидранты урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

13) Илексаз авылы Комсомол урамы 2 нче йорт күрсәткечләре стендларын яңарту өчен баннерлар сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Илексаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы

Илексаз авыл җирлеге башлыгы: Гыйльфанов Ф. М.